| | |
|---|---|
| СОВЕТ БУРНАШЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>БУРНАШ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

_______________ с. Татарское Бурнашево _______________

№54-239

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Бурнаш авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 июлендәге 26-115 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 7.3.3 пунктын түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«2.1) коррупциячел һәм башка коррупциячел хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе докладының, анда аны башкаруның фактлагы шартлары бәян ителә, һәм муниципаль хезмәткәрне аның ризалыгы белән һәм коррупциячел хокук бозуны кылу фактын тану шартларында (ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендәге хокук бозулардан тыш) муниципаль хезмәткәрнең язмача аңлатмасы»;

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәнең текстын яңа редакциядә расларга (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге башлыгы С.В.Бурукин